**СОВЕТ КАЗАКЛАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422722, Республика Татарстан, Высокогорский район, с.Казаклар , ул. Советская, д. 5

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАЗАКЛАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422722, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Казаклар авылы, Совет ур., 5

тел./факс 8(84365) 6-34-30 e-mail: Kazak.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**от 26 январь 2024 г.** **№ 96**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 28 маендагы 145 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясенең 14.05.1993 № 4979-1 «Ветеринария турында» законы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 28 маендагы 145 номерлы карары (06.09.2021 №37 редакциясендә) нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кетрергә:

VIII бүлекнең 183 пунктының икенче абзацында «терлекчелек продуктлары» сүзен «хайваннардан алынган продукция» сүзләре белән алыштырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адресы буенча рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru. Интернет челтәрендә урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан (халыкка чыгарылган) көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Совет Рәисе,
Казаклар авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Сафин